# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге составына керүче Су-Елга (шул исәптән Норма урманчылыгы) торак пунктында 2025 елга үзара салым кертү турында

№ 1 17 октябрь 2024 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлегенең Су-Елга (шул исәптән Норма урманчылыгы) торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кече Кирмән авыл җирлеге Су-Елга (шул исәптән Норма урманчылыгы) торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2025 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Су-Елга (шул исәптән Норма урманчылыгы) торак пунктында урамнарны яктырту буенча энергия саклаучы лампалар алу һәм урнаштыру;
- Су-Елга торак пункты- Тынычлык урамындагы юлларны вак таш җәеп ремонтлау. (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Су-Елга (шул исәптән Норма урманчылыгы) торак пунктында җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту.

3. Әлеге карарны Кече Кирмән авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кече Кирмән авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Х.Х.Мубаракшин